

10 февральдә Мордовия Дәvләт Жыелышы (Председатель Государственного Собрания) рәисе Владимир Чибиркин, Мордовия Хокvмәте (Председатель Правительства РМ) рәисе Дмитрий Поздняков, РМ буенча Баш федераль инспектор (Главный федеральный инспектор по РМ) Михаил Сезганов, Мордовия прокуроры Сергей Лапин, хокук саклау структуралары житәкчеләре һәм вәкилләре катнашында Мордовиянен гомуми юрисдикция судларынын 2022 елдагы эшенә йомгак ясау буенча кинәшмә узды. РМ Югары Суды рәисе Валерий Кияйкин докладында билгеләп vткәнчә, гомуми юрисдикция судлары һәм җәмәгать судьялары тарафыннан узган ел 150 менгә якын граждан, административ эш һәм материаллар, административ хокук бозулар турында 38 менгә якын эш, 3320 жинаять эше каралган.

Судлар закон чыгару һәм башкарма хакимият белән актив катнашалар. Бу уртак эшкә унай бәяне Мордовия Дәvләт Жыены рәисе бирде. Владимир Чибиркин суд органнары һәм тобәк парламенты хезмәттәшлегенен топ юнәлеше - җәмәгать судьялары эшчәнлеген тәэмин итv, дип искәртте. Әйтик, узган ел Дәvләт Жыелышы сессияләрендә 17 җәмәгать судьясы билгеләнгән (11 вәкаләтләр (полномочий) срогы чикләнмичә һәм 6 – срогы 3 елга).

2022нче елда Мордовия Дәvләт Жыелышы, республика Югары Суды белән берлектә, «Россия Федерациясе субъектларында җәмәгать судьяларынын гомуми саны һәм суд участоклары саны турында «Федераль законнын 1 статьясына vзгәреш кертv һәм Мордовиядә суд участоклары санын бер берәмлеккә (44тән 45кә кадәр) арттыру һәм бер җәмәгать судьясы вазыйфасын остәмә кертv олешендә» федераль закон проекты эшләнде. Шулай ук җәмәгатьчелек вәкилләрен Мордовия Республикасы Судьяларынын квалификация коллегиясенә билгеләv дә уздырыла.

«Суд җәмәгатьчелегенен игътибар vзәгендә гражданнарнын, бигрәк тә халыкнын аз якланган категорияләренен, шул исәптән пенсионерларнын, ятимнәрнен, инва-лидларнын хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау мәсьәләләре булырга тиеш. Бу аеруча бvген махсус хәрби операция ясауга бәйле. Республикада яшәvче һәр кеше профессиональ суд ярдәме һәм яклау алачагына ышанырга тиеш», - дип билгеләп vтте Владимир Чибиркин.

Традиция буенча йомгаклау кинәшмәсендә Мордовиянен судьялар корпусы вәкилләренә бvләкләр тапшырылды.

**Наилә НАСЫРОВА әзерләде**